# Нәсыйхәт

Җомга 27 сентябрь 2013 №24

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы


## Яңалыклар

### МӘДРӘСӘДӘ ТИКШЕРҮ ҮТТЕ

**22нче август көнне мәдрәсәдә тикшерү булып үтте.** Казан шәһәреннән килгән мөфтинең урынбасары Рөстәм хәзрәт Батыров, укыту эшләре буенча җаваплы Айнур хәзрәт һәм укыту бүлегенең баш белгече Руслан хәзрәт Таһиров җитәкчелегендәге махсус комиссия уку-укыту документларын тикшерде, мәдрәсәдә укытуны оештыру эшләре белән танышты. Тикшерү азагында комиссия вәкилләре үзләренең тәкъдимнәрен һәм киңәшләрен җиткерделәр.

### КУРСЛАР ОЕШТЫРЫЛА

Россия Ислам Университеты базасында 1нче октябрьдән алып 7нче октябрьга кадәр махсус курслар оештырыла. Анда Мамадыш мәдрәсәсе мөгаллимнәре дә катнашырлар дип көтелә.

### КОНФЕРЕНЦИЯДӘ КАТНАШТЫЛАР

**25нче сентябрь көнне мәдрәсә җитәкчелеге һәм мәдрәсәнең барлык мөгаллимнәре Россия Ислам Университеты бинасында узган фәнни-практик конференциядә катнаштылар.** Әлеге конференциядә дини белем бирү системасында күзәтелгән кайбер үзгәрешләр каралды.



**Мәдрәсә мөгаллимәләре Эльвира Хәбибуллина һәм Венера Яруллина конференциядә.**

## Мөхәррир сүзе

# МӘДРӘСӘБЕЗГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!



**–Габдрахман хәзрәт, мәдрәсә эшчәнлегендә беренчел максат нидән гыйбәрәт?**

– Без бүген җәмгыятебезнең рухи асылын торгызырга, яшәтергә, саклап калырга күп мөмкинлек тудырылган заманада яшибез. Мамадыш мәдрәсәсенең максаты исә, әлеге рухи мирасны саклап калу һәм киләчәк буыннарга ирештерү, шулай ук югары әхлаклы, дини белемнәр белән коралланган, җәмгыятебезгә файдалы шәхесләр тәрбияләү.

**–Мамадыш мәдрәсәсенең башка дини уку йортлар белән чагыштырганда нинди үзенчәлекләре бар?**

–Беренчедән, без шәкертләрне күбрәк үз районыбыздан тупларга тырышабыз. Әлеге принципка таянып эш итү, районны яшь дини белгечләр белән тәэмин итүдә уңай роль уйнамый калмый. Икенчедән, шәкертләр мәдрәсәдә уку белән беррәттән, шәһәрнең мәктәпләрендә һәм һөнәри көллияттә дә укый алалар. Әлеге шәкертләр өчен махсус җәдвәл төзелгән, алар шимбә һәм ял көннәреннән тыш өйләгә кадәр мәктәптә укып, өйләдән соң мәдрәсәдә гыйлем ала алалар.

**–Укулар нинди программа белән укытыла?**

–Уку-укыту программасы Әбу Хәнифә мәзһәбе тәгълиматенә нигезләнгән һәм дини һәм дөньяви фәннәрне үз эченә алган. Бу программалар Татарстан Җөмһүрияте Диния Нәзарәте тарафыннан расланган.

**–Мәдрәсәдә нинди чаралар уздырыла?**

–Мәдрәсәдә уку-укыту алымнарын камилләштерү, укытучы мөгаллимнәрнең педагогик осталыгын күтәрү өстендә даими эш алып барыла, педагогик киңәшмәләрдә тәҗрибә уртаклашу була. Мәдрәсә шәкертләре укудан буш вакытларын файдалы үткәрәләр. Алар өчен һәрдаим төрле кызыклы чаралар уздырылып тора: төрле спорт ярышлары, һәр елны табигать кочагына чыгып, ял итүләр гадәткә кертелгән, Коръән уку бәйгеләре үтә, сугыш ветераннары белән очрашулар, төрле әдәби кичәләр, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә булышу, мәктәпләрдә наркоманиягә каршы чыгышлар ясау–болар барысы да мәдрәсәдә үткәрелеп килә торган чаралар. Шулай ук чыгарылыш кичәләре дә тирән эчтәлекле, истә калырлык итеп уздырыла. Мамадыш мәдрәсәсе базасында балалар лагерьлары да (җәйләүләре) үткәрелә. Бу чаралар мәктәп балаларының каникул вакытына туры китерелеп эшләнә.

**–Мәдрәсәдә ничә укытучы укыта?**

–Мөгаллимнәр төркеме 8 кешедән тора. Аларның күбесе дини белем белән беррәттән дөньяви белемгә дә ия.

**–Мәдрәсәне тәмамлаган укучыларга нинди документ бирелә?**

–Уку программасын үзләштергән укучыларга диплом тапшырыла. Аларга имам-хатыйб һәм башлангыч дини белем укытучысы белгечлеге бирелә. Әлеге документ белән мәдрәсәне тәмамлаучы республиканың мәчет -мәхәлләләрендә имам, мөәзин һәм мәчет каршысындагы укуларда мөгаллим-мөгаллимә булып эшли ала.

**–Бүгенге көндә мәдрәсәне ничә кеше тәмамлады?**

–Мәдрәсәнең ачылуына 5 ел. 2011нче елда мәдрәсәнең беренче чыгарылышы булды. Шул арада мәдрәсәнең кичке бүлеген 83 кеше тәмамлады.

**–Кичке уку бүлегендә уку ничек оештырылган?**

–Бу бүлеккә махсус урта һәм дөньяви югары белем алган яшьләр белән беррәттән, өлкән яшьтәгеләр дә киләләр. Кичке бүлектә укыту ике төркемгә бүлеп алып барыла: эшләп укучы шәкертләр атнаның өч көнендә кичке якта, ә хезмәттә булмаганнар атнаның өч көнендә иртәнге якта, өйләгә кадәр укыйлар.

**–Әйтеп үтелгәннәрдән тыш тагын нинди укыту төрләрен кулланасыз?**

–Ял көннәрендәге оештырылган укуларда яшьләре кечкенәрәк булган шәкертләр укый. Мәдрәсәдә шулай ук имамнарның һәм абыстайларның белемнәрен арттыру курслары да эшләп килә. Мәдрәсәдә укып чыгып шәһадәтнамәләр алган укучыларга да бирелә гыйлемнәрен тагын да камилләштерергә мөмкинлекләр тудырылган. Алар атнага бер тапкыр мәдрәсәгә килеп укып китә алалар. Читтән торып уку бүлеге дә каралган. Әлеге бүлектә укучылар, елына ике тапкыр мәдрәсәгә килеп 10 көн дәверендә укып китәләр.

**(Ахыры 4нче биттә)**

# БИШЕКТӘН ЛӘХЕТКӘ КАДӘР ГЫЙЛЕМ ЭСТӘ!

Гыйлем алу–Ислам динендә атаклы булган 40 фарызның иңәһәмиятлеләреннеңберсе. Гыйльме рух фәне өйрәтүе буенча бишектән, ягъни баланың теле ачыла башлаганчы ата-ана баласын танып-белүгә өйрәтә башларга бурычлы. “Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән кермәс ”, –ди халык. Бу–бүген фән белән исбатланган хакыйкать. Аллаһы Раббыбыз безгә бу турыда 1400 ел элек аңлаткан. 2 ел баланы имезү дәверендә бала рухи, акыл, физик һәм әхлакый тәрбия нигезләренең 80 % ана сөте белән алганын дәлилли бүгенге фән. Инде баланың теле ачылу белән аңа гыйлем бирү һичшиксез үтәлергә тиешле гамәлләрдән санала: Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләне тану, күркәм холык тәрбияли башлау, яманны яхшыдан аеру, ягъни саваплы һәм гөнаһлы гамәлләрне аңлату һ.б. Әйе, ата-анага билгеле булырга тиеш шул хакыйкать: тиешле тәрбия һәм гыйлем алмаган балага киләчәктә туган гаиләсенең, үзенең булачак уку яки хезмәт коллективына файда китерә алмаячак. Һәм икенчедән яшьтән алган гыйлемен иҗади фикерләп һәм аны өзлексез үстереп (тирәнрәк үзләштерү) тормышта куллана белүе дә мөһим. Шулай төпле һәм иҗади белемле кешеләр әлегә безгә башка планеталардан (һавадан) төшмиләр ягъни без аларны үзебез тәрбияләргә тиеш...

Балаларга аң-белем бирү һәм аларны тәрбияләү юлында ата-аналар арасында гына түгел, югары белемле укытучылар арасында да дөрес булмаган һәм шул ук вакытта киң таралган алымнар кулланалар. Дөрес, бу сорау гаилә һәм мәктәпнең көндәлек тормыш сорауларыннан башлап җәмгыятебезнең нигезенә һәм өскормасына да барып тоташа. Без, үзебезнең мөмкинлектән чыгып, бу сорауны аз гына булса да ачыкларга һәм аннан чыгу юлларын күрсәтергә телибез. Иң гади һәм мәгънәсез алымнарның берсе–баланы ялкаулыкта тиргәү һәм җәзага тарту. Бәлки балага ярдәм итәргә кирәктер. Гыйльме рух фәне өйрәтүе буенча аң-белем алу–катлаулы гамәл, ягъни баш мие тиресенең бөтен өлкәсе (маңгай, чигә, баш түбәсе һәм баш чүмече) яки кирәк вакытта баш миенең аерым өлеше җитәкчелек итә, аң-белем алу процессы белән. Балаларның (бигрәктә 12 яшькә чаклы) баш мие яхшы сыгылмалы ягъни акыллы һәм сау-сәламәт бала сәләтле аң-белем алырга. Ә сәләт һәр балада үзгә, ягъни һәр акыллы һәм сау-сәламәт бала билгеле бер тирәнлектә сәләтле билгеле бер фән яки фәннәр буенча. Бу сорау әлегә гыйльме рух фәнендә тулысынча ачыкланмаган, ягъни билгеле бер баланың нәрсәгә сәләтле икәнен тулысынча ачыклый (әйтә) алмый. Мин дә кечкенә чагымда (дөрес эти белән әни өметсезлеккә бирелмәгәннәр) уку материалларын үзләштерә алмаганмын. Ә кайда булган төп сәбәпләр? Тумыштан сулагайлык, сөйләм теленең соң ачылуы һәм баш миенең сул як ярымшарының өстенлекле булуы... Ә укытучы елата-елата уң кул белән язарга өйрәтте, өйдә исә сул кул белән яздым. Әти-әни бу турыда укытучыдан белсәләр дә, миңа сүз әйтмәделәр, зур рәхмәт үзләренә. Гыйльме рух фәне әйтүе буенча сулагай балага ирек бирелергә тиеш, ягъни аның баш миенең үсешен тоткарлап аң-белем алу дәрәҗәсен кимсетергә ярамый. Ә баш миенең сул як ярымшарының өстенлекле булуы баланың логикага тартым фәннәрдә сәләтлерәк булуын сөйли.

Бу турыда атаклы кешеләр тормышыннан:

–Александр Пушкин математика фәненнән тоташ икелегә укыган;

–дөньякүләм билгеле чагыштырмалык теориясе авторы Альберт Эйнштейн унбиш яшендә, өлгермәве сәбәпле, гимназиядән куылган;

Антон Чехов 3нче сыйныфта тел фәннәре аркасында ике ел утырган;

–Максим Горькийны Казан университетының филология факультетына кабул итмәгәннәр.

Нәтиҗә ясап, дидактикага артык тирән кермичә һәм һәрдаим әл-Хәлим вә әл-Кәрим булган Аллаһы Тәгаләгә таянып, баланың темпераментын, кызыксынуларын һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып оештырылган аң-белем бирү уңышсыз кала алмый.

Әлегә безнең җәмгыятьнең төп ялгышын тарих кире какса да ягъни укыту-тәрбияләү системасы әлегә ислам дине белән тыгыз бәйләнмәгән. Хәзерге мәгариф системасы баларны әзерли бу дөнья өчен генә. Ә бит, аң-белем һәм тәрбияләү системасы ислам гакыйдәсе белән бәйләп алып барылган очракта безгә Бөек Аллаһ талантлы шәхесләр тәрбияләргә мөмкинлек бирәчәк. Бу тарих белән исбатланган. Җир шарының атаклы һәм талантлы шәхесләре Исаак Ньютон, Кеплер, Леонардо да Винчи, Эйнштейн, Владимир Фортов – Русия Фәннәр академиясе академигы һ.б. дөнья фәненә зур өлеш кертәләр. Аллаһы Тәгалә юлында булулары аркасында гына. Китерергә була бик күп мисаллар шул турыда, фәнгә бирелгән талантлы шәхесләр һәм галимнәр бердәнбер көнне мәҗбүр булалар танырга Аллаһ Раббыбызның барлыгын һәм берлеген. Мәсәлән, хәзерге заман физика фәнендә атаклы немец галиме В.Хелсенерг: “Мин ... атомдагы энергияне ничек файдаланырга мөмкин булуы хакында әйттем. Хәзер күңелдә шундый сорау туарга мөмкин –кем бу кечкенә генә урынга шундый зур көчне куйган? Һәм ул бу сорауга җавап бирә: “Бу сорауларга Ислам дине генә җавап бирә аладыр. Мин һәм минем галим дустым Ханх бу турыда шулай уйлыйбыз. “Гомумән физиклар белдергәнчә: “Галәм аңлы тереклек ияләре өчен, әйтерсең, заказ буенча ителгән...”. Физикларга билгеле галим Джон Полкинхорд: “Галәм шаккатыргыч дәрәҗә дә төп-төгәл һәм бер-берсенә ярашлы кануннар буенча барлыкка килгән. Шуны аңлаган кеше бу дөньяның очраклы рәвештә килүенә ышанмас, теләсә-теләмәсә дә дөньяның барлыкка килүенең билгеле бер максаты булуы турында уйлый башлар”–, ди. Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә, Ислам гакыйдәсе белән бәйләнмәгән һәм икенчедән ялган материалистик “фәнни ” карашлар нигезендә гыйлем бирү һәм тәрбияләү җәмгыятебездә хайвани тормыш алып баручыларны гына арттыра. **Ислам гакыйдәсе нигезендә гыйлем бирү һәм тәрбияләү ул безнең балаларны, үсмерләрне һәм яшьләрне изге җанлы кеше итә торган бердәнбер юл...**

Мәгълүм ки кешенең өч асылы бар: җаны, акылы һәм бәдәне ( тән ). Ә ничек итеп тәрбияләргә Аллаһы Тәгалә риза булырлык итеп үзара гармониядә кешенең бу өч асылын? Галимнәргә билгеле булганча кешенең асылы белән бүгенге педагогика фәне бернәрсәдә эшли алмый, ягъни рухи камиллеккә ирешүне булдыра ала торган хәлдә түгел. Ә әлегә безнең җәмгыятьтә рухи тәрбия мәдрәсә һәм мәчеттән башка җирдә алып барылмый. Мәктәп исә баланы дин гыйлеменнән мәхрүм итә, ягъни Аллаһ Сөбханә вә Тәгалә белән бала арасындагы мөгамәләне танымый... Акыл халәте Ислам гакыйдәсе (дөньяга карашы) белән бәйләнмәгән. Ягъни тәкъвалык сыйфатларыннан башка рухи камиллеккә ирешү мөмкин түгелдер дип фаразлыйм. Ислам динендә тәкъвалыкның 6 дәрәҗәсе бирелә. Теориягә бик тирән кермичә генә шуны әйтәсе килә, тәкъвалыкның асылы бәйләнгән кешенең күркәм әхлагы белән. Ягъни савап эшләсәк җаныбыз сөенә һәм канәгатьлек хисе ала, инде гөнаһ кылсак, борчылабыз һәм вөҗдан газабы тоябыз. Инде тәүбә иткәч җаныбыз тынычлана...

Бу–безнең иҗтимагый тормышка кагыла торган зур кимчелек;

–заманави мәсьәләләр чыганагы: әхлаксызлык, эчкечелек, һәртөрле тәртипсезлек һ.б.;

–телебезнең һәм милли асылыбызның югала баруы...

–ахирәт тормышына төкереп карау, ягъни аңа әзерләнмәү ...

Сорауга дөрес җавапны бүгенге көндә бары тик мәдрәсәләрдә генә табарга мөмкин...

**КАМИЛ ХИСМӘТОВ,**

**мәдрәсәнең 2нче курс шәкерте.**

♦ *Илгизә Нәзир иҗаты*

# Ярый әле гамьнәрем бар...

## (нәсер)



Газиз Аллам, Раббым, Аллаһым!
Мине ягымлы, йомшак , саф, нечкә күңелле, якты җанлы, йомшак бәгырьле, кечкенә генә җан ияләрен дә кызгана торган, кешеләрне яратучы, матурлыкка соклана белә торган, гүзәллек-хозурлыкны үз куллары белән тудырырга сәләтле, хисләргә бай, хыялый-романтик рухлы итеп яратканың өчен чик-чамасыз рәхмәтләрем, мактауларым Сиңа! Туган халкымның, җирдә яшәү дәверендә бихисап күп авырлыклар–газаплар күргән, сагыш-хәсрәтләр кичергән газиз кавемемнең җыр-моңнарына гашыйк, гармун көй-аһәңнәренә мөкиббән, аның сәнгать әсәрләре, мәдәният җимешләре белән ихластан, чын күңелдән сокланырга сәләтле булуым, биниһая бай, камил, гүзәл, йомшак, нәфис-затлы, ягымлы, назлы, асыл, зәвыклы ана телемне ихластан үз итүем дә Синнән, газиз Аллаһым, Раббым, Ходаем, Хак Тәгаләм! Хисапсыз мактауларым Сиңа, и, Раббым !

Җәйге иртәдә тәрәзәдән урамга карыйм. Ямь-яшел агач-куаклар әкрен искән талгын җилдә тибрәләләр... Күкрәгемне тутырып тирән итеп сулыш алам. Суларга–һавам, эчәргә–суым, яшәргә–илем, кадерен белергә–туган җирем, ихлас яратырга газиз балаларым, якын кешеләрем булуына Сиңа, Аллаһым, тагын бер тапкыр олуг рәхмәтләремне, чиксез мактауларымны, хәмед-сәнәләремне әйтеп, дога кылам. Кичер мине, Раббым, аңлап һәм аңламыйча, яшерен һәм ачык кылган гаеп-гөнаһларым, ялгыш-хаталарым өчен! Инәлепләр сорыйм Синнән, ихластан ялварам, үтенәм. Кемнедер рәнҗеткән булсам, зинһар, дип, Хак Тәгаләм, Сиңа дәшәм, аларга мине кичерергә, гафу итәргә мөмкинлек тудыр!

Кардай ап-ак, әйтерсең лә, асыл- затлы бәрхеттән ясалган йомшак мендәрдәй кабарган, күк йөзен иңләп йөзүче мамык болытлар белән зәвыкланган-бизәлгән зәңгәр киңлеккә багам. Күзләремне, зур итеп ачып, биек-биектәге диңгез- дәрьяга теким. Бакчамда елмаеп, көлеп утыручы көнбагыштай сап-сары, түп-түгәрәк кояш яна анда! И гүзәл, иркен, якты фани дөнья! Безгә кадәр дә булгансың, Аллаһыбыз теләсә, бездән соң да калырсың! Кыямәт көненең кайчан киләсен бер Ходай гына белә бит!

Тышка чыгам. Тирә-юньгә күз салам. Йортыбыз алдындагы бакчамны матурлап-ямьләп, зиннәтләп утыручы, үз кулларым белән сөеп-назлап үстергән хуш исләр таратучы гүзәл чәчәкләремә сокланып, аларга күз сирпим. Йа, кодрәти Аллам! Раббым! Хак Тәгаләм! Нинди олуг нигъмәтләр, хозурлык-гүзәллекләр бүләк иттең миңа бу җәйләрдә дә! Бөтен җиһан илаһи нурларында коена. Җанга–тынычлык, күңелгә–рәхәтлек, сафлык- пакълек иңә! Рәхмәт Сиңа, газиз Аллам! Агачларда чут-чут килеп кошлар сайрый. Һавада нәни җан ияләре–бөҗәкләр безелди, аллы-гөлле, нәфис-затлы күлмәкләр кигән күбәләкләр оча. Тагын да алга китеп, болай дип уйлыйм: суларыбызда балыклар йөзә, урман-болыннарыбызда киек җәнлекләр яши, таулардан, челтер-челтер килеп, җырлап, көмеш сулы чишмәләр агып чыга... Никадәр нигъмәтләр! Сиңа чын күңелдән рәхәтләнеп данлау-мактаулар яудыра-яудыра, хисапсыз шөкераналар кыла-кыла, яшисе дә яшисе иде бит безгә, синең колларыңа!

Раббым! Син безгә нигъмәтләр белән зиннәтләнгән, баетылган җирдә яшәргә мөмкинлек тудыргансың. Бары да бар. Кадерен генә бел дә, әрәм-шәрәм, исраф итмичә, бәрәкәт белән файдалан гына. Балаларыбызга, оныкларыбызга да калдырасы иде яшәү чыганакларын, Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләрен!!!

**Күңелемә, ирексездән, шигырь юллары килә:**

*Ярый әле язларым бар,*
*Сайрар кошлар,*
*назларым бар,*
*Иснәп туймас*
*гөлләрем бар,*
*Күктә аем, кояшым бар.*
*Ярый әле көйләп туймас,*
*Якты моңлы*
*җырларым бар.*
*Ярый әле чишмәләрем,*
*Елга-күлләр, суларым бар.*
*Ярый әле кырларымда*
*Уйнак-шаян җилләрем бар.*
*Арышларым, сагышларым,*
*Рәшәләрдә тургаем бар.*
*Ярый әле ак карларым,*
*Җәйге җылы яңгырым бар.*
*Ярый әле саф хисләрем,*
*Уйларым бар,*
*гамьнәрем бар.*
*Ярый әле һәрчак көтеп*
*Яши торган әнкәем бар.*
*Ярый әле туган туфрак,*
*Изге җирем, үз илем бар...*

## Килегез, дин кардәшләрем, мәдрәсәгә!

**Бисмилләхир-рахмәнир-рәхим Мамадыш мәдрәсәсенең дини-иҗтимагый газетасы булган “Нәсыйхәт”нең 23 нче санын сөенеп-шатланып, гаҗәпләнеп укыдым.Эчтәлекле, бай телле, мәгънәле итеп чыгаргансыз аны. Сезгә Аллаһыбызның рәхмәтләре яусын!**

Мин быел, Хак Тәгаләнең биргәненә хисапсыз шөкерана кылып, мәдрәсәгә 4нче курска укырга барам. Форсаттан файдаланып, шуны әйтәсем килә: газиз дин кардәшләрем! Килегез мәдрәсәгә укырга, дин гыйлеме алырга! Дөньяга, тормышка башка төрле карый башлавыгызны сизми дә калырсыз! Шәкертләрне бик дини, гыйлемле, талантлы мөгаллим-мөгаллимәләр укыта биредә. Авызларына гына каратып тоталар алар безне. Аңлаешлы итеп сөйлиләр, укыталар, кем әйтмешли, чәйнәп бирәләр, йотып җибәрәсе генә кала. Без биредә олы бер гаилә булып яшибез, сәбәпсез дәрес калдырмыйбыз.

Газетаны укыганда шуңа игътибар иттем: аннан җылылык, иман нуры бөркелә, чөнки шәһәребезнең каләм остасы Илгизә ханым Нәзированың язу стиле, алымы аермачык тоемлана. Үз вакытында район газетасында хезмәт куйган Илгизә Миркадәм кызының шигырьләр бәйләме дә “Нәсыйхәт”нең соңгы санына нур өстәгән, аны күркәм, тирән эчтәлекле иткән. Шигырьләрендә Аллаһыга ихластан ышануы, Аны олылавы, данлавы, мактавы ачык сизелә. Якты, матур, күңел җылысы белән сугарылган шигырь юллары күңелемә хуш килде, җаныма бәлзәм, шифа -дәва булып ятты. Аллаһы Тәгаләбез аны үзенең яраткан бәндәләреннән әйләсен! Өстәп шуны әйтим. Без бу ханым белән “ Изге нур” мәчетенә җомга намазларында бергә булабыз. Ул агымдагы уку елында шулай ук мәдрәсәгә килеп шәригать гыйлеме нигезләрен өйрәнә башларга җыена. Иншә Аллаһ, тырышлыгы, сабырлыгы белән морадына җитәр, дигән өметтә калам. Чын күңелдән иҗат уңышлары телим аңа. Ходай Тәгаләне зурлаган, мактаган, данлаган, матур эчтәлекле шигырьләр, хикәяләр язуын дәвам итсен. Без, дин юлында йөрүчеләр, аларны көтеп калабыз. Гарәпчә укырга өйрәнү, минемчә, бик савaплы эш. Ни өчен дигәндә, күпләр аңлый булса кирәк: бу телдә пәйгамбәребез Мөхәммәд сөйләшкән. Аңлашыла ки, максатчан кеше үзлегеннән дә шактый гыйлем эсти ала. Әмма мондый сүз дә бар бит: ”Китаптан укып кына ерак китеп булмый, остаз да кирәк.” Минем белән килешерсез, дип уйлыйм.

Якташларым, шәһәрдәшләрем! Сезгә ихлас күңелдән әйтәсе килгәнем шул: без, өлкән курсларда укучы шәкертләр, сезне мәдрәсәбездә укучылар итеп күрергә өметләнәбез. Рәхим итегез!

**ӘЛФИЯ ЗАРИПОВА,**
4нче курс талибәсе

# МӘДРӘСӘБЕЗГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

**(Ахыры. Башы 1нче биттә)**

Шулай ук мәдрәсәдә барлык теләүчеләргә гарәп теле һәм “Тәҗвид кагыйдәлә”рен өйрәнү буенча аерым курслар да ачу мөмкинлеге бар.

**–Киләчәккә нинди планнар белән яшисез?**

–Мәдрәсәнең киләчәккә планнары да зур. Шәкертләргә аерым бинада торак булдыру, мунча төзү, яшелчә саклый торган склад булдыру, үз-үзен финанс яктан бәйсез итәрлек җитештерү тармагын эшләтеп җибәрү, үз умарталыгын булдыру, гәҗит, китаплар бастыру өчен типография ясау, барлык уку классларын интерактив такталар белән һәм кирәкле әсбаплар белән җиһазлау, үз машина паркын булдыру. Бу эшләр күп хезмәт таләп итә, әмма Аллаһының рәхмәте зур. Ният кылырга гына кирәк.

**–Габдрахман хәзрәт, якташларыбызга нинди теләкләрегез бар?**

–Мин телләгә булган һәркемне мәдрәсәгә укырга чакырам. Бер көнлек гомеребезне фани дөнья өчен генә, мал җыеп кына үткәрмик. Без, мөселманнар, үз динебезнең таралуын, аның нуры бөтен тарафны яктыртып торуын һәм бу дингә ияргән халыкларның бәхетле булуларын телибез. Әмма, әгәр без үзебез шушы ислам диненең нигезләрен яхшы белмәсәк, аны кирәкле дәрәҗәдә ихтирам итмәсәк һәм аның васыятьләрен тотмасак, безнең бу өметләребез коры хыял гына булып калачак. Динне хөрмәтләү исә аны өйрәнү һәм шуның белән гамәл кылудан гыйбарәт. Шулай булмаганда, дин туфрак астында күмелеп торучы алтын кебек яшерелеп торыр. Гыйлем – Исламның нигезедер. Бу дөньяда иң зур байлык–ул иман байлыгы! Шуны онытмыйча, һәр ике дөнья бәхетенә лаеклы булып яшәсәк иде.

**Әңгәмәне ЭЛЬВИРА ХӘБИБУЛЛИНА алып барды.**

# Әби хаты

**(Дәвамы. Башы 22нче санда)**

Вакытым җитеп килә, кызым. Шушы сүзләрне язу миңа авыр бирелсә дә, мин аны сизәм кызым. Бәлки син кайтып өлгерә алмассың, шуңа да сиңа әйтәсе үтенечләремне мин кәгазь битенә язам.

Өебезне синең исемгә язып калдырам. Берүк өйгә йозак элдермә. Тәрәзәләргә такта кактырма. Алма бакчасы миңа бик кадерле икәнен син бик яхшы беләсең. Кияүгә чыгып шушы йортка күчкәннән бирле диярлек мин алмагач утырттым. Бабаң, әйтә торган иде: “Әй карчык, кемгә калыр инде бу байлыгың, әрәм калса, жәл була бит,”– дип, шул вакытта мин сине уйлап куйдым. Син безнең өметебез, кызым. Өйне һәм бакчаны бары сиңа гына ышанып тапшырам.

Бабаең үлеме мине тетрәндерсә дә, ул вакытта янымда син булдың. Синең ярдәмең белән мин яңадан терелдем. Син киткәч, ялгызлык мине урап алды. Ул чактагы газапларымны Аллаһы Тәгалә беркемгә дә күрсәтмәсен. Ялгызлык ул чир кебек, кызым, син аннан котыласың гына, ул тагын сиңа ияр. Му-



енсамны шкафта табарсың. Минем истәлек итеп сакла син аны, кызым. Миңа шундый үтенечләр белән хатымны тәмамлыйм инде, балам. Сиңа бәхет телим, Ходай рәхмәтенннн ташламасын. Әмин!

Әбиең Мәликә.

3нче сентябрь, 1997 ел.

Сиринә еларга теләсә дә, күзләреннән яшьләр тамmaды. Ул хатны кире конвертка салды да, ишеккә таба борылды.

–Син кая, Сиринә?– дип сорады Ирек.

–Әби өенә. Әйдә икәү.

–Ул бит бикле. Ничек керербез соң?

–Мин ачкычның кая яшерелгәнен беләм. Киттек әйдә.

Сиринә, әбисенең өенә килеп җиткәнче, бер сүз дә эндәшмәде. Ирек күңелсез хәбәрне Саймә ападан ишеткәч, Сиринәне ялгызын калдырмаска кирәк дигән карарга килде. Чыннан да, Сиринә ачкычны тиз тапты. Өй эченә кергәч, ул бераз тын гына басып торды, аннары шкафтан чия төсендәге муенсаны алды. Ирек бакчаны барлап кергәндә дә, Сиринә һаман да муенсаны тоткан килеш уйга батып утыра иде.

–Сиринә, син тәртиптәме?

–Ирек, мин авылда калам.

–Мин синнән шушы сүзләрне көткән идем.

–Тик син...

–Минем өчен борчылма. Бар да яхшы. Сиңа күчене эшләре белән булышасымы?

–Апа белән сөйләшмәгән әле. Бәлки ул булышыр. Син иртәгә китәсеңме?

–Әйе, иртә белән.

–Ирек, гафу ит мине.

–Сиринә, кирәкми. Мин барысын да аңлыйм.

Ирек озак тормый чыгып китте. Ә Сиринә буш өйдә яктылык эзләгәндәй, тирә-якка карады, тик урамда инде караңгылык төшкән иде.

**ФАЯГӨЛ ТАЛИПОВА.**

Көек-Ерыкса авылы.

## Укырга чакырабыз

# Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

**Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе 2013-2014 уку елына шәкертләр туплавын дәвам итә.**

Белгечләр әзерләү көндезге һәм кичке уку рәвешендә алып барыла.

Көндезге бүлеккә ир-егетләр кабул ителә (шәһәребездән һәм авыллардан). Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә 3 тапкыр ашау–эчү белән тәэмин ителәләр. Уку вакыты–дүрт ел. Урта белем алу икенче лицей нигезендә алып барыла.

Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә.

**УКЫРГА КЕРҮ ӨЧЕН КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕНӘ ТҮБӘНДӘГЕ ДОКУМЕНТЛАРНЫ ТАПШЫРЫРГА КИРӘК:**

1) Гариза
2) Белем турында таныклык
3)086-формасында сәламәтлек турында белешмә
4) Паспорт (копия)
5) 3х4 үлчәмендә 4 фотосурәт
6) №26 формасында индивидуаль медицина картасы.

Намаз укырга өйрәнергә һәм дин белемен үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли. Бу бүлекләргә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган.

**Безнең адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М. Җәлил урамы 8/28,**

**Телефоннар:**

**3-19-17, 89172802391**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 400 данә.**